**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №51-9 « 23» апрель 2026 ел.

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2009 елның 21 гыйнварындагы 248-34 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлегенең муниципаль казнасы турындагы Нигезләмә хакында” карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлегенең муниципаль казнасы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 63 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2018 елның 22 августындагы 202-30 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениеесе турында нигезләмә хакында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ турында Нигезләмә нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2009 елның 21 гыйнварындагы 248-34 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлегенең муниципаль казнасы турындагы Нигезләмә хакында” карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлегенең муниципаль казнасы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында санап үтелгән нигезләр буенча муниципаль милеккә сатып алынган, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.3 пункты нигезендә казна мөлкәте составына кертелергә тиешле объектларны вәкаләтле орган Нигезләмә нигезендә гамәлгә кертү, аны алга таба файдалануны билгеләүче, аны тотуга һәм эксплуатацияләүгә акчалар бүлеп бирү күләме һәм тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. вәкаләтле орган карары муниципаль милек объектларын районның муниципаль казна составыннан төшереп калдыруга нигез булып тора:

1) хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукларында муниципаль казна мөлкәтен муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә беркетү турында;

2) Россия Федерациясе субъектына, муниципаль берәмлекләргә район казнасы мөлкәтен тапшыру турында;

3) районның муниципаль милек хокукын:

- гражданлык-хокукый килешүләр кысаларында (хосусыйлаштыру, сату, бүләк итү, алмашу);

- суд карарларын үтәгәндә;

мал-мөлкәт юкка чыкканда;

- милекче карары белән милекне бетергәндә.

- 5.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Районның муниципаль казнасы мөлкәтенә техник хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле орган тарафыннан Башкарма комитетның язма ризалыгы белән «Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә төзелә торган муниципаль контракт нигезендә юридик һәм физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр җәлеп ителергә мөмкин.дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар".».

2. Әлеге карарны түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo. tatarstan.ru һәм “Интернет” мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча http://aznakayevo.tatarstan.ru.урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин